ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.05.2019 Алексеевск ш.т.б. № 205

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы милкендә булган күчемсез милек объектлары турында мәгълүматны бастырып чыгару тәртибен раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Дәүләт Советының 2018 елның 5 апрелендәге утырышы йомгаклары буенча (2018 елның 15 маендагы Пр-817 ГС номерлы) муниципаль милектә булган объектлар турында мәгълүматны бастырып чыгаруны һәм актуальләштерү өлешендә Россия Федерациясе Президенты йөкләмәләре исемлеген гамәлгә ашыру максатларында

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез милек объектлары турында мәгълүматны бастырып чыгару тәртибен расларга (Кушымта).
2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе М. Р. Гайсинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыров**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
15.05.2019 № 205
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез милек объектлары турында мәгълүматны бастырып чыгару тәртибе**

1. Әлеге тәртип «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – Интернет челтәре) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез милек объектлары турында, аның белән кызыксынучы барлык кешеләр файдалана алуны тәэмин итү максатларында, мәгълүматны бастырып чыгару процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә муниципаль берәмлекләр милкендәге күчемсез милек объектлары турындагы мәгълүматны Интернет челтәрендә бастырып чыгару өчен муниципаль берәмлекнең рәсми сайты булып http://alekseevskiy.tatarstan.ru/rus/perechen-obektov-munitsipalniy-sobstvennosti.htm. тора.

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез милек объектлары турындагы мәгълүматны бастыруга вәкаләтле орган булып, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының авыл (шәһәр) җирлекләре белән төзелгән килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы тора.

4. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының шәһәр, авыл җирлекләренең һәм Алексеевск муниципаль районының муниципаль милке Реестрына кертелгән биналар, йортлар, җир кишәрлекләре кебек күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат басылып чыгарылырга тиеш, Россия Федерациясе законнары нигезендә рөхсәт ителгәнчә, үтеп керү чикләнгән объектлар турында мәгълүмат бастырып чыгарылырга тиеш түгел.

5. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат, әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә, күчемсез милек объектлары (биналар, йортлар, җир кишәрлекләре) турында мәгълүмат рәвешендә басылып чыга.

6. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез милек объектлары турында бастырып чыгарылган мәгълүматны актуальләштерү вәкаләтле орган тарафыннан квартал саен гамәлгә ашырыла.

**Башкарма комитет**
**эшләре белән идарә итүче** **Г.А. Юсупова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районының
муниципаль милкендәге күчемсез
милек объектлары турында
мәгълүматны бастырып чыгару
тәртибенә кушымта

Алексеевск муниципаль районының муниципаль берәмлекләре Ресстрына кертелгән күчемсез милек объектлары (биналар, йортлар, җир кишәрлекләре) турында мәгълүмат

| № | Милек исеме (кадастр номеры) | Урнашкан урыны (адрес) | Мәйданы кв.м | Максатчан билгеләнеше | Кыенлыклар | Чикләү |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |